РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Чистопольский муниципальный район
Татарско-Баганинское сельское поселение

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Чистай муниципаль районы
Татар Баганалысы авыл жирлеге

422963, РТ, Чистопольский район, с.Татарская Багана, ул.Советская,18А/1, тел.(884342) 3-63-10,
E-mail:Tbag.Ctp@tatar.ru

Постановление Карар

№2 11.02.2020 ел

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Татар Баганалысы авыл җирлеге башлыгының
2016 елның 30 мартындагы
8 номерлы карарының
үз көчен югалтуын тану хакында

«Муниципаль вазыйфа, яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны, яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 30 мартындагы «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында»гы 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), Татар Баганалысы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына элү юлы белән халыкка хәбәр итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http:/chistopol.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татар Баганалысы авыл
җирлеге башлыгы Р.Р.Җәббаров